Апрель
2018

# Газета "Импульс"



## Бу чыгарылышта



Кызыклы кеше белән әңгәмә


Равил Бохараев кем ул?





Бабаем, төсең итеп
саклыйбыз гармуныңны...

# Кызыклы кеше белән әңгәмә




Тиздән илебез Бөек Җиңүнең 73 еллыгын билгеләп үтәчәк. Бөек Ватан сугышында илбасарлар белән көрәштә һәлак булганнар турында .... генә сөйләп булмый. Шулар арасында үз гомерләрен илләре өчен корбан иткән күпме язучылар һәм шагыйрьләр бар. Сугышта республикадан 124 язучы катнашкан, шуларның 34е Ватанны саклап һәлак булган.Татар халкының бөек уллары Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш, Нәби Дәүли, Фатих Кәрим ... сугыш кырларында мәңгегә ятып калган әдипләрнең туган илләрендә сөйгән хатыннары, яраткан балалары калган. Рәсемдә Фатих Кәримнең кызы Ләйлә Кәримова. Аңа әтисенең каберennән алып кайткан шушы язуы бик якын, кадерле. Ләйлә ханым сугыш чоры баласы. Ул да әтисен сугыштан кайтуын бик көткәндер... Без Ләйлә ханым белән күптән түгел мәктәптә очрашуда күрештек. Аның белән өендә озак итеп сөйләшеп утырдык.

- **Ләйлә ханым, сез әтиегезне хәтерлисезме?**
- Әни безгә әтием турында бик күп сөйләде. Мин әтиемне күрмәдем диярлек. Миңа бер ай булганда 1937 елны аны кулга алганнар. Әти төрмәдән кайтканда миңа дүрт яшь булган. Ләкин, мин ул вакытларны хәтерләмим.
- **Әтиегез белән сугыш вакытында очрашмадыгызмы?**
- 1942 елның май аенда яралангач, ул өйгә кайтты. Аны госпитальгә Казанга җибәргән. Башта өйгә керде, аннан әнием аны госпитальгә озатты. Шунда ул берничә поэма, шигырьләр язды. 1 май көнне бик иртән кемдер ишек какты. Ачсак, әтием килеп керде. Без аңа сөендек. Ул "туктагыз, туктагыз" диде, чөнки яраланган иде.
- **Фатих Кәрим фронтта һәлак булган. Ул кайларда сугышта катнаша?**
- Ул сугышны Мәскәүдән башлады, аннары Украинага, Белоруссиягә житте. 1944 елда аны инженерлар училищесына водолаз-саперлыкка укырга җибәрделәр. Анда кече лейтенант дәрәҗәсе алган. Әти өч тапкыр яралана, өченче яра үлемгә китерә. Фатих Кәрим яралангач та госпитальгә китмәгән. 1945 елның 19 февралендә әтием Көнчыгыш Пруссиядә, хәзерге Калининрад өлкәсендә күмелгән.
- **Әтиегез һәлак булуы турында кайдан белдегез?**
- Без ул көннәрдә хатларны бик сирәк ала идек. Беркөнне безгә посылка килде. Аның эчендә шинель, әтинең итекләре, немец - урыс сүзлеге, ордены, дәфтәре, безнең фотолар иде. Бераздан үлем кәгазе- "похоронка" килде. Анда "Ваш муж, лейтенант Фатих Карим, погиб 19 февраля 1945 года, похоронен в районе деревни Каверне", дип язылган. Сугыш беткәч, әни аның каберен эзләргә тотынды. Ун ел эзләде. Аннары каберне ике литва тапты. Анда алюминийдән ясалган һәйкәлчек һәм аңа пычак белән "Лейтенант Фатих Карим, татарский поэт" дип уелган булган. Ул кабердә ун кеше яткан.
- **Багратионовскига күчергәндә ун җәсәт арасыннан Фатих Кәримнең гәүдәсен ничек аерып тапканнар?**
- Аның шинеле булмаган. Күмгәндә аны плащпалаткага төргәннәр. Багратионовск – элекке немец шәһәре. Анда хәзер төрле милләт кешеләре яши. Алар Фатих Кәримне беләләр, укыйлар. Аңа яңа хәтер ташы куйдылар. Мин Багратионовскига берничә тппкыр бардым, мәктәп балалар белән очраштым, хәзер шушы шәһәрдә Фатих Кәримнең кем икәнен бөтенесе дә белә. Ә Фатих Кәрим үзе 1945 елның 19 февралендә Көнчыгыш Пруссиядә, хәзерге Калининрад өлкәсендә күмелгән. Аның җәсәде Багратионовски шәһәрендә.


Хәбибуллин Нияз, 8 А

## Гаиләм—горурлыгым

Татарстанның танылган рәссамы Ирина Константиновна Колмогорцева 2015 елның 7нче ноябрендә 86 яшендә бакыйлыкка күчте. Аның иҗаты күпкырлы иде. Иҗатының төп юнәлеше булып, Татарстанның тарихын һәм мәдәниятен, күренекле шәхесләребезнең язмышын сурәтләү торды. Аеруга зур җылылык белән ясалган картиналары арасында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга, Казаныбызның үткәненә һәм киләчәгенә багышланган хезмәтләре аерым урын алып тора.



Гаиләбездә әбием генә иҗат кешесе түгел иде. Аның тормыш иптәше Георгий Зяблицев та Татарстанның күренекле скульпторы булып танылган шәхес иде. Берсе - рәсем укытучысы, икенчесе - архитектор. XX йөзнең икенче яртысындагы республика сәнгате үсешенә әһәмиятле өлеш керткән Татарстан Республикасының халык рәссамы Ирина Константиновна Колмогорцева һәм Татарстан Республиканың атказанган мәдәният хезмәткәре Георгий Аркадьевич Зяблицев иҗатына багышлап каталог чыгарылды. Анда сәнгать белгечләренең мәкаләләре һәм рәссамнарның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан белешмәләр дә урын алган.




Әбиемнең балалары да аның эшен дәвам итеп, шушы юлны сайлаганнар. Мин дә узган ел сәнгать мәктәбен кызыл дипломга тәмамладым. Киләчәктә әбием һәм бабамның эшен дәвам итәргә уйлыйм.

9 Асыйныфы укучысы Федотова Алина

## Бабам истәлеге

Гармун белән танышуым көтелмәгәндә булды. Әлбәттә, мин гармунның нәрсә икәнлеген беләм, музыка мәктәбен тәмамладым, гитарада, барабанда уйныйм. Берничә ел элек “Син гармунда уйнап җырлыйсың”, - дисәләр, мин бик тә аптырар идем.



Ял көннәре, гадәттәгечә, әбиемә булышырга килдем. Өйнең ерак почмагындагы чоланда тузан суырткычы эзләгәндә, күзем борынгы йөзаклы зур чумаданга төште. “Татар тотып карамыйча ышанмый”, - диләр. Иске йозаклы чумаданнан “Чайка-2” гармуны килеп чыкты. Өске өлешендә истәлек язуы. “Галәметдингә туган көненә абыйсыннан. 1986 ел”. Кызыксынып, төймәләргә баса башладым. Гаҗәеп матур музыкаль тавышлар чыгарган гармун миңа бик ошады һәм әбинең ризалыгы белән аны өйгә алып кайттым. Минем бабам гармунчы булган икән. Моны мин инде әтиемнән ишеттем, мин дә үзем өйрәнергә булдым. Кич белән интернеттан гармунда уйнау дәресләрен карадым. Бер анта эчендә мин үзлектән гармунда уйный башладым. Ишетеп уйнау минем өчен җиңелрәк булды. “Әпипә”, “Тала, тала”, “Катюша” җырлары минем беренче уңышларым.

Безнең татар халкы уен коралларында оста уйнавы белән дан казанган. Мин - халкымның үткәненә, аның мәдәниятенә битараф булмаган яшьләрнең берсе. Тормышыбызга техника көннән – көн нык үтеп кергән заманда халык көйләре онытылмасын, гармун тавышлары тынмасын иде.

Әти-әниемә, әбиемә, дусларыма минем яңа шөгылем ошый. Киләчәктә мин баянда уйнарга өйрәнергә телим.

11А сыйныфы укучысы Хамадеев Азат

# Татар әдәбияты белән кызыксынучы укучыларыбыз

Быел февраль аенда Ибраһим Халфин исемендәге 13нче Республика фәнни-гамәли конференциясе узды. Миңа анда катнашырга насыйп булды.Конференциядә катнашучылар шактый күп, районнардан да килүчеләр бар иде.Мин Аяз Гыйләҗевкә багышланган секциядә катнашып, беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләндем.



Аяз Гыйләзев-татар халкының бөек язучысы. Аның тууына быел 90 яшь тулды. Татар теле укытучыбыз белән без "Аяз Гыйләзевнең “Өч аршын җир” әсәрендә туган туфракның бирелеше"дигән темага фәнни эш башкардык . Фәнни эшем аша шуны җиткерергә теләдем: кеше дөньяны куа, мал җыя, ләкин тормышта иң кыйммәт әйбер – кешелекле булу, Туган җир. Теге дөньяда өч аршын җир дә җитә.

Жюри составында таләпчән татар укытучылары һәм язучының хатыны Накыя ханым да бар иде. Аның: “Татар телен онытмагыз, татарча укыгыз, сөйләшегез, ул сезнең ана телегез, туган телегез. Татарча яшик, татарча үрчик,"- дигән сүзләре аеруча истә калды. Мондый конференцияләр күбрәк булсын, үзебез дә активлык күрсәтсәк иде.Телебезне саклауда аз булса да өлеш кертик.

9А сыйныфы укучысы Галеев Расул

## Үткәнне белмәгәннең киләчәге юк

Мин, Хабибуллин Нияз, 8 А сыйныфы укучысы. Бу уку елында лицебызда үткән “Фән көннәре” конференциясендә катнашып, җиңү яуладым.

“Үткәнне белгән кешенең генә киләчәге бар”, - диләр. Ә үткәндә минем яшьтәшләрем нинди шартларда яшәгәннәр соң? Безнең бәхетле һәм мул тормышта яшәүебез өчен үзләрен аямыйча көрәшкән сугыш чоры балалары нинди булганнар? Аларның язмышын чагылдырган әдәби әсәрләр белән кызыксыну миндә “Фатыйх Кәрим иҗатында бала образы” темасына тукталу хыялын тудырды. Мин аның шигырь һәм поэмалары белән таныштым. Авыр сугыш елларында иҗат ителгән 150ләп шигырь, 8 поэмасы бүген дә туган илне яратуның, батырлыкның гүзәл үрнәге булып тора. Шагыйрь иҗаты белән кызыксынуым тагын да артты. Мин аның кызы Ләйлә апа белән очрашырга булдым. Фатих Кәрим белән кызы язмышын шигъри юллар белән аңлатырга телим.

Кызчыгына бер ай гына булган
Шул чак аны кулга алганнар,
Әниләре күңеленә яра
Йөрәгенә сагыш салганнар
Бала авазына мохтаҗ булып,
Дүрт ел үткәч кайткан йортына
Бер ай хәтта яши алмаган ул
Китеп барган сугыш кырына.
Күңелендә бала тавышының
Кайтавазы чыңлап торганга,
Иҗатында бала образын
Куйгандыр ул алгы планга.



Фатыйх Кәрим иҗатын өйрәнү минем күңелемдә ватанпәрвәрлек хисләрен тагын да үстерде. Туган илемнең чын патриоты булып үсәсем, аның күг══н аяз, халкын тыныч һәм мул тормышта бәхетле итеп күрәсем килә. Киләчәктә халкымны яклаучы милли җанлы юрист буласым килә.

8А сыйныфы укучысы Хабибуллин Нияз

## Беркем дә,  бернәрсә дә онытылмый

Сугыш… Ишетүгә үк җанны өшетүче, йөрәкне калтыратучы бу сүз үз эченә күпме фаҗига сыйдырган. Төзелмәгән гаиләләр, тумаган балалар, кайтмаган ирләр, тол калган хатыннар, ятим калган балалар язмышы – шушы бер сүзгә сыйган. Безнең гаиләне дә сугыш читләп үтмәгән. Нуретдинова Хәнисә Каримовна - минем әбинең әнисе. 1911нче елда Актанышта туган. 1941 нче елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергән. Ул вакытта Ватанны сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелгән. Әбекәй дә, 30 яшендә  өйдә 4 баласын калдырып, Туган илен юлбасарлардан саклар өчен  ул сугышка киткән. Балаларны әнисе һәм энесе караган. 2 елга якын фронтта була, ләкин яралангач, аны өенә кайтаралар. Картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына калган авылда тормышны алып барырга кирәк иде – игенне дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугышка җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, бик күп салымнар да түләргә кирәк иде. Әмма тыл халкы сынатмаган, сыгылмаган. Авылда да кызлар, картлар, балалар колхоз эшен җигелеп тартканнар. Көне-төне эшләсәләр дә, ашарларына җитмәгән. Икмәкне фронтка озатырга кирәк була. Җәй көннәрендә балтырган, кузгалак, ачы каки, төче каки, кычыткан, чөгендер яфрагы – барысы да ризыкка әйләнгән. Бу авыр елларда авыл язмышы ил язмышына кушылган. Ирләре, уллары, туганнары яу кырында батырлыклар күрсәткәндә тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшләгәннәр. Минем әбиемнең әнисе үстергән игеннәр күпме сугышчыларга ярдәм итә.

Әбекәйнең ире Нуретдинов Кыяметдин  дә 1910нчы елны Актанышта туган. 30 яшендә сугышка киткән. Ул аяусыз сыгышларның берсендә контузияләнә.  Күпмедер вакыт Ул кайткан сугыштан , ләкин ул инвалид сугышның 2 группысы  булып кайткан. Аның бик күп медаллар бар.

Әбием сугыш чоры баласы. Сугыш башланганда аңа  4 яшь була. Тормышында аңа бик күп авырлыклар күрергә туры килгән, ләкин сугыш китергән кайгыны ул бер дә онытмый. Күп вакыт сүзен гел сугыш турында башлый. Хәзерге вакытта ул гаиләбез, якыннары өчен  матурлык өлгесе.

Хәзер инде Бөек Ватан сугышы тәмамланганга да 73 ел. Сугыш яралары акырынлап булса да төзәлгән, сугыш эзләрен вакыт тузаны күмә, күңелдә бары хәтирәләр генә яшәп килә.

7 В сыйныфы укучысы Низамова Әминә

## Бурычлы без сезгә, Ветераннар!



Бөек Ватан сугышы безнең гаиләне дә читләп узмый.

Мөхәммәтгата улы Муллазөфәр бабайны (әниемнең дәү әтисе) да 1942 нче елның августында сугышка җибәрәләр.Шулвакытта аңа 18 яшь була. Зөфәр бабай башта хәрби элемтәчеләр әзерли торган курслар үтә, аннары 40нчы аерым артдивизионында телефонист булып, фронтка китә. Сугышта батырларча көрәшә, ләкин 1944 елның 17 нче июнендә каты артилерия уты астына эләгеп, уң аягы бик авыр яралана. 5 ай госпитальдә дәвалангач, 1944 нче елның ноябрендә туган авылына кайтып төшә. Бабай “За победу над Германией”  һәм юбилей медальләре белән бүләкләнә.



Һәр ел без гаиләбез белән 9нчы майда “Үлемсез полк” чарасында катнашабыз. Миндә бу чарада катнашу зур горурлык хисе уята, бабамның Бөек җиңүгә  керткән өлеше зур, аны медальләр, орденнар белән генә үлчәп бетереп булмый. Аның бөеклеге безнең күңелләрдә.

11 А сыйныфы укучысы Шакиров Булат

# Тукай и Сайдашев



Салих Замалетдинович Сайдашев родился он 3 декабря 1900 года. Отец Сайдашева умер, так и не увидев сына. Салих воспитывался в семье сестры, Её муж Шигаб Ахмеров принадлежал к прогрессивным кругам татарской интеллигенции. Шигаб Ахмеров – мой прадед, и именно он помог раскрыться музыкальному дарованию мальчика. Салих сначала играл на гармонике. А потом мой прадед приобрел рояль.

Шигаб Ахмеров практически заменил ему отца. В доме собирается весьма деятельная татарская интеллигенция той эпохи, где маленькому Салиху было подарено судьбой общение с известными людьми того времени.



Здесь Салих Сайдашев и познакомился и хорошо общался с Габдуллой Тукаем. Я вам расскажу об одной их встрече.

Моя бабушка – Дильбар Замалеевна Саинова-Ахмерова, в своей книге «Салих Сайдашев. Страницы жизни и творчества композитора» писала о том вечере.

«В тот вечер Габдулла Тукай зашел к Ахмеровым. Салих и Тукай всегда хорошо общались. Тукай не мог слушать спокойно некоторые произведения, но игру Салиха Сайдашева на рояле он любил.

В тот раз Салиха попросили поиграть его любимое произведение. Сайдашев очень хорошо играл, Габдулла слушал его внимательно, а через какое-то время и вовсе запел, словно соловей.

Все наблюдали за игрой Салиха и слушали пение Тукая. Но вдруг Габдулла начал кашлять кровью, да так, что капли попали на клавиши инструмента. После этого, его увезли в больницу».

«Это был послений раз, когда Тукай приходил к нам», - говорил Шигаб Ахмеров.

Мне очень нравятся произведения Сайдашева, особенно «Марш Советской Армии» и «Вальс» из драмы «Наемщик».

Я считаю, что Салих Сайдашев – не только основоположник татарской музыки, но и является одним из лучших композиторов.

Идут года, а музыка великого композитора нам по-прежнему близка, мила нашему сердцу. Я согласна с тем, что Салих Сайдашев оставил весомый вклад в татарскую музыку, культуру.

Асия Ахмерова, ученица 7 А класса

Много ли заимствованных тюркских слов, так называемых тюркизмов в русском языке? Хронологически можно выделить несколько слоёв тюркских заимствований:

1. Унаследованные тюркизмы из праславянского языка. Чекан, болван, товар. Предполагается тюркское посредство для слов баран (иранское) и книга (китайское?).
2. Древнерусские заимствования домонгольского периода. Боярин, шатёр, богатырь, ватага, жемчуг, кумыс, лошадь, лошак, орда. Слово собака, по наиболее распространённой версии иранское, О. Н. Трубачёв считал тюркским. Особую группу составляют несколько булгаризмов, заимствованных через посредство старославянского языка: бисер, ковчег, кумир, сан, чертог.
3. Древнерусские заимствования из тюркских языков периода Золотой Орды. Ям, ямщик, ярлык, казак, караул, кочевать, деньга, казна, казначей, тамга (откуда таможня), барыш, хозяин, харч, кирпич, жесть, лачуга, серьга, алмаз, изумруд, брага, буза, арбуз, ревень, с, миткаль, бязь, тесьма, башмак, колпак, фата, чулок, кафтан.
4. Заимствования XVI—XVII веков. Чулан, амбар, войлок, чемоадан, саранча, сундук и т.д. Заимствования этого времени особенно многочисленны, что объясняется огромным культурным влиянием Османской империи. Это влияние распространяется даже на начало XVIII века: к петровской эпохе относятся такие известные заимствования как башка, изъян, карандаш, фарфор и т. д.
5. Заимствования XVIII—XX веков. Камыш, кабан, кибитка, плов, майдан, короб, бакалея, ералаш, ханжа, буран и т.д.

«Я служу Аллаху и своему народу – и в этом вижу смысл жизни. Во мне живет желание рассказать о нас, татарах, и нашей великой культуре всему миру» Р. Бухараев.

Поэт, прозаик, переводчик, драматург, лауреата Государственных премий им. Г.Тукая и им. М.Джалиля Равиль Бухараев родился в 1951г. Окончил он наш любимый 131 лицей и механико-математический факультет КГУ. Уже в школе Равиль начал писать стихи, с большим желанием участвовал в общественной жизни школы и класса. На вопрос: «Как вы, математик, пришли в поэзию?», он ответил: «Так это почти одно и то же! Познание мира разными средствами. Когда известного математика Гильберта спросили, кем стал один из его учеников, он ответил: «Поэтом. Для математики у него было слишком мало воображения». В поэзии и математике главное – мыслить, думать. Думать о, казалось бы невозможном, доказывать невозможное и искать невозможные пути к возможному». Он является автором более 30ти книг стихов и прозы, переводов татарских поэтов на русский, английский, венгерский языки. «Вокруг Тукая. Повесть в стихах», «Поэзия Золотой Орды», «Волшебные сны Апуша», «Казань. Зачарованная столица», «Ислам в России. Четыре времени года» и другие. С 1990 работал продюсером на русской службе Би-би-си. Часто приезжал в Казань и любил это делать. Любил он и свой народ. «Татары - это звездный народ с мировой культурой. В Золотой Орде были поэты уровня Данте! А посмотрите, каких великих людей мы подарили миру. Правда, их таланты часто раскрываются вне Татарстана. Это факт, если татарин или татарка не чувствуют над собой «потолка», то их вообще не догонишь! Примеров - масса!» - говорил он в одном из интервью.





О Казани написаны сотни книг, ей посвящено множество стихов. Книга Р. Бухараева «Сказ о Казани» занимает среди них особое место. Он шел к ней всю жизнь, изучая историю родного города не только по книгам, но и по первоисточникам. Книга имеет своеобразную форму изложения. Несмотря на то, что это историко-публицистический труд, на каждой странице чувствуешь, что автор – поэт. Только поэт может назвать главу песней и писать о «Лучезарной Казани», «Зачарованной столице», Казани «Неповторимой и величавой».



Что мы знаем о Золотой Орде? Только то, чему нас когда-то учили. Оказывается, что не все так просто. Золотая Орда, несмотря ни на что, была примером и образцом не только кочевой, но и оседлой, более того, городской цивилизации. И именно Р.Бухараев вел в рускоязычный обиход высокие образцы поэзия Золотой Орды. Он собрал и впервые перевел на русский язык стихи и поэмы Хисама Кятиба, Сайф-и Сараи, Хорезми, Кутба и нескольких анонимных авторов.



Равил Бухараев очень любил творчества Тукая. Написал две поэмы о поэте. “Мы мало понимаем Тукая, мы совершенно не представляем масштабы его дарования. Его гениальность не в том, что он соответствует нашим чаяниям и порывам, это само собой, а дело в том, что наше счастье заключается в том, что он у нас есть, и он навсегда остается нашим нравственным символом” Многие стихотворения Тукая можно прочитать на русском и английском языке благодаря Р. Бухараеву.

“Его «твоческие достижения являются… для нас открытием века не только татарской культуры, но и общероссийской и общечеловеческой… Произведения Бухараева – интелектуальная гордость нации»,- писал Чингиз Айтматов. Читайте произведения Равиля Бухараева и каждый из вас найдет что-то родное, что-то близкое для себя.

Все фотографии из личного архива Алеевой Идилии Ильтазаровны. Она учились в одном классе, 131 лицее. 1. 10 кл. Сценка “На экзамене” 2. 15 лет после окончания школы 3.На 60летнем юбилее в министерстве Культуры 4. На презентации книги “Отпусти мою душу на волю” ИЗО музей.

Жалдак А., Деганова В.

# Мәктәп тормышы мизгелләре

10нчы апрельдә безнең лицейда хәйрия ярминкәсе узды. Лицей укучылары һәм аларның әти-әниләре үзләре пешергән тәм-томнар, кулдан эшләнгән әйберләр, ясаган рәсемнәр алып килделәр. Ярминкәгә килүче һәр кеше үзенә охшаган әйберне таба алды. Открыткалар, сыерчык оясы,



варенье, муенсалар, энә капчыклары, картиналар, төрле савытлар, брелоклар, кулдан ясалган сабыннар, төрле сувенирлар, бәйләнгән әйберләр, үзләре пешергән чүпрәсез ипи, төрле бәлешләр, кекслар һәрберсенең күңеленә хуш килде. Бу төрлелеккә карап без балаларның, әти-әниләренең никадәр иҗади кеше булулары турында күзаллый алабыз. Сатучы укучыларның итагатьлеге турында әйтми мөмкин түгел. Алар үзләренең товарлары турында җентекләп сөйлиләр. Һәрхәлдә мондый сүзләрдән соң бер әти-әни дә сатучылар яныннан әйберсез китми. Мәктәп укучылары үзләренең музыка коралларында уйнап җырлаулары белән дә ярминкәгә килүчләрне сокландырдылар. Гитарада, гармунда алар башкарган татар, рус җырларын тыңлап, хәйрия ярминкәсенә үз өлешләрен керткән әти-әниләр күп булды. Ярминкәдә җыелган акча Анжелла Вавилова исемендәге фондка тапшырылды. Бу хосписта ятучы авыру балаларның хәлен күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтер дип уйлыйбыз.

7 Б сыйныфы укучысы Заһидуллина А.

Гадәттәгечә, апрель аенда лицеебызда татар теле атналыгы узды. Атналыкның иң тантаналы



өлеше – бу концерт. 23нче апрельдә актлар залына телебезгә гашыйк, аның язмышына битараф булмаган укучылар җыелды. Быел концертны мин 9 Б сыйныфы укучысы Йосыпов Тимур белән алып бардым. Һәр чара үзенчә башкалардан аерылып тора. Бу юлы да шулай булды. 8Д сыйныфы укучылары “Башак” исемле рус халык әкиятен сәхнәләштергәннәр. Балачактан таныш әкиятне татар телендә ишетү күпләрне гаҗәпләндерде. Татар җырларын бөтен сыйныфлары белән җырлаучылар да бу концертта күп иде. 9В “Алмагачлары”, 7Б “Әткәй - шикәр, әнкәй- бал”, 8 В “Бәхеттә, шатлыкта” җырларын башкардылар. Шәмсетдинова Сания башкаруындагы татар халык биюе һәр тамашачының күңеленә хуш килде. 9 А сыйныфы укучылары, 7 В сыйныфы укучысы Низамова Әминә, 10 А сыйныфы укучысы Шарафеева Ләйсән, М.Җәлил, Г.Тукай шигырьләрен укучыларның күңеленә үтеп керерлек итеп башкардылар. Сәйдәшевның “Музыкаль мизгелләр” әсәрен 7Б сыйныфы укучысы Бакирова Камилә искиткеч итеп пианинода уйнады. 9Д сыйныфыннан Мортазина Оля Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәреннән өзекне яттан сөйләде.



Һәр елдагыча чараны Тукайның “И, туган тел” җыры белән тәмамладык.

9 А сыйныфы укучысы Гайнуллина Динара

Подписывайтесь на нашу группу ВКонтакте:https://vk.com/impulse131

*Над выпуском работали: Юсупов Данил, Кулакова Александра, Гайнуллина Динара, Загидуллина Аделя, Ахмерова Асия, Шакиров Булат, Низамова Амина, Жалдак Анастасия, Деганова Валерия, Хабибуллин Нияз, Галиев Расул, Хамадеев Азат. Большое спасибо Алеевой Идилие Ильтазаровне .*